МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ һәм азык-төлек МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ Казан шәһәре БОЕРЫК

05.12.2014 № 230/2-пр.

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәменә федераль бюджеттан керә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә бәйсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясе субъектларына 2014 елда федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләрне бүлү турында” 2014 елның 29 ноябрендәге 2406-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәменә федераль бюджеттан керә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына (алга таба - Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктындагы 1.1. пунктчасын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1. 2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә бәйсез ярдәм күрсәтүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе» (1 нче кушымта);»;

1.2. Боерыкның 2 пунктындагы 2.1. пунктчасына түбәндәге пунктчаны өстәргә:

«2.1.1. 2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә, туфракны төп (көзге) эшкәртүне исәпкә алып, бәйсез ярдәм күрсәтүгә белешмә-исәп-хисап формасын (49нчы кушымта);»;

1.3. Боерыкның 2 пунктындагы 2.2. пунктчасына түбәндәге пунктчаны өстәргә:

«2.2.1. 2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә, туфракны төп (көзге) эшкәртүне исәпкә алып, бәйсез ярдәм күрсәтүгә белешмә-исәп-хисап формасын (50нче кушымта);».

2. Боерыкка 1, 49, 50нче кушымталарны әлеге Боерыкка 1, 2, 3нче кушымталар нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның
5 декабрендәге 230/2-пр номерлы боерыгына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының 2014
елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы
боерыгына 1нче кушмта

**2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә бәйсез ярдәм күрсәтүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип 2014 елда үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче барлык милек рәвешләрендәге авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекчелек өлкәсендә бәйсез ярдәм күрсәтүгә федераль бюджеттан субсидияләр (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрен сайлап алу критерияләре түбәндәгеләр:

а) үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату;

б) милектә яисә аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары булу.

3. Субсидияләр бирү максатлары түбәндәгеләр:

а) авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә агротехник эшләр комплексын үткәрүгә 1 гектар чәчүлек мәйданына чыгымнарның бер өлешен каплау;

б) авыл хуҗалыгы җитештерүенең экологик иминлек дәрәҗәсен күтәрү;

в) туфракның уңдырышлылыгын һәм сыйфатын арттыру, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең фитосанитар торышын яхшырту.

4. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре өчен субсидияләр күләме - 1 176 667,8 мең сум:

а) 834 312 мең сум, 1 гектар чәчүлек мәйданына түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V=П \times (158{,}0 + (2{,}36 \times У)+(45{,}17 \times И_{ппмр})) \times 1{,}35$$

Монда:

V — күчерелергә тиешле субсидияләр күләме, сум;

П — план буенча чәчүлек мәйданы, гектарда, ул алга таба факттагы чәчүлек мәйданнары турындагы мәгълүмат белән раслана, шуның нигезендә 2014 елга чәчү турында рәсми статистик исәп-хисап әзерләнә (алга таба - чәчү турында мәгълүмат);

158,0 — бер гектар чәчүлек мәйданына минималь ставка, сум;

2,36 — 1 центнер бөртекклеләр җитештерүгә ставка, сум;

У — авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, бер гектар чәчүлектән җитештерелгән бөртекклеләрнең уртача центнер берәмлегендә, соңгы 5 елда чәчүлек мәйданнары һәм авыл хуҗалыгы культураларының уңдырышлылыгы

турындагы мәгълүмат (алга таба - уңыш җыю турында мәгълүмат) һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын бөртекләләр бирәмлегенә күчерүнең коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы нигезендә. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең биш еллык тарихы булмаган очракта, эшчәнлекнең факттагы чоры исәпкә алына, ә яңа оешкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр өчен — муниципаль район буенча 5 ел эчендәге уртача уңдырышлылык кабул ителә;

45,17 —җирләрнең уңдырышлылыгы буенча бер гектар чәчүлеккә уртача ставка, сум;

$И_{пп\ мр}$ — Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача исәпләнгән индексы, ул Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечен исәпләү методикасын раслау турында» 2013 елның 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика буенча, «Татарский» агрохимия хезмәте үзәге» Федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» Федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - агрохимия хезмәте) тарафыннан бирелгән күрсәткечләр нигезендә, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә билгеләнә;

1,35 — туфракның уңдырышлылыгын арттыру һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең фитосанитар торышын яхшырту буенча чаралар үткәрүнең төзәтмә коэффициенты. Ул чәчү мәйданыннан кимендә 7 процент чиста пар җирләре булган һәм (яисә) чәчү мәйданнары структурасында кимендә 3 процент борчак чәчүлекләре булган авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре өчен кулланыла;

б) 342355,8 мең сум, 1 гектар чәчүлек мәйданына түбәндәге формула буенча исәпләнә:

V=П x 107,09 x 1,3

Монда:

V — күчерелергә тиешле субсидияләр күләме, сум;

П — чәчүлек мәйданы, гектарда, 2014 елдагы чәчү турында мәгълүмат нигезендә;

107,09 – бер гектар чәчүлек мәйданына минималь ставка, сум;

1,3 — авыл хуҗалыгы культураларының уңышын булдыру өчен туфракта продуктив дым туплау максатларында туфракны төп (көзге) эшкәртүне вакытында төгәлләүне кызыксындыру өчен төзәтмә коэффициенты. Ул туфракны төп (көзге) эшкәртүне 2014 елның 20 октябренә кадәр фараз күрсәткечләреннән 90% мәйданда башкарган авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр өчен кулланыла.

5. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба - Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирүгә гариза;

соңгы 5 елда чәчү мәйданнары һәм авыл хуҗалыгы уңышын җыю турында субсидия алучылар тарафыннан таныкланган мәгълүмат. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренең биш еллык тарихы булмаган очракта, эшчәнлекнең факттагы чоры исәпкә алына, ә яңа оешкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр өчен — муниципаль район буенча 5 ел эчендә уртача уңыш;

чиста пар җирләренең һәм борчак мәйданының булуы, аларның процент чагыштырмасы турында мәгълүмат;

2014 елның 20 октябренә туфракны төп эшкәртүнең торышы турында мәгълүмат;

1 гектар чәчүлек мәйданына тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп-хисап, әлеге боерыкка 11 нче һәм 49 нчы кушымталар формасы буенча.

6. Идарә:

а) субсидия алуга гаризаны кергән көндә үк журналга терки, ул номерланырга, тегелеп куелырга һәм мөһер белән беркетелергә тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгәннән соң 15 эш көненнән дә артмаска тиеш);

в) күрсәтелгән документлар нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча 1 гектар чәчүлек мәйданына тиешле субсидияләр турында әлеге боерыкка 12 нче һәм 50 нче кушымталар формасы буенча җыелма белешмә-исәп-хисапны төзи һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Министрлык) тапшыра.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә ачылган үзенең шәхси счетыннан 10 эш көне эчендә Идарәләрнең Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына акчаларны күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма белешмә-исәп-хисаплар субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора. Идарә 5 эш көне эчендә субсидияләрне авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларларның комплекты тулы булмау;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Бирелгән субсидияләр аларның максатчан билгеләнеше буенча тотылмау фактлары һәм (яисә) субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелү фактлары ачыклану буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң алтмыш көн эчендә федераль бюджет керемемә кайтарылырга тиеш.

Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет керемемә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

9. Министрлык авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

10. Тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә һәм Идарәләр башлыкларына йөкләнә. Закон бозучыларга законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

11. Бюджет акчаларының максатчан кулланылышын Министрлык тишереп тора.

2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә
авыл хуҗалыгы товарлары
җитештерүчеләренә бәйсез ярдәм
күрсәтүгә федераль бюджет акчалары
исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

**Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә субсидияләр күләмен исәпләү өчен туфрак уңдырышлылыгы индексы**

| № *т/с* | Муниципаль район исеме | Агрохимия хезмәтләренең күрсәткечләре буенча туфрак уңдырышлылыгы коэффициенты ($К_{мр}$) | Туфрак уңдырышлылыгы индексы (*пп.мр 71 05 мр) |
|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 75 | 0,9473 |
| 2 | Азнакай | 93 | 0,7640 |
| 3 | Аксубай | 82 | 0,8665 |
| 4 | Актаныш | 84 | 0,8458 |
| 5 | Алексеевск | 85 | 0,8359 |
| 6 | Әлки | 62 | 1,1460 |
| 7 | Әлмәт | 81 | 0,8772 |
| 8 | Апас | 78 | 0,9109 |
| 9 | Арча | 73 | 0,9733 |
| 10 | Әтнә | 66 | 1,0765 |
| 1 i | Баулы | 84 | 0,8458 |
| 12 | Балтач | 76 | 0,9349 |
| i3 | Бөгелмә | 95 | 0,7479 |
| 14 | Буа | 86 | 0,8262 |
| 15 | Югары Ослан | 69 | 1,0297 |
| 16 | Биектау | 70 | 1,0150 |
| 17 | Чүпрәле | 87 | 0,8167 |
| 18 | Алабуга | 67 | 1,0604 |
| 19 | Зәй | 79 | 0,8994 |
| 20 | Зеленодольск | 74 | 0,9601 |
| 21 | Кайбыч | 79 | 0,8994 |
| 22 | Кама Тамагы | 76 | 0,9349 |
| 23 | Кукмара | 73 | 0,9733 |
| 24 | Лаеш | 76 | 0,9349 |
| 25 | Лениногорск | 82 | 0,8665 |
| 26 | Мамадыш | 70 | 1,0150 |
| 27 | Менделеевск | 71 | 1,0007 |
| 28 | Минзәлә | 68 | 1,0449 |
| 29 | Мөслим | 82 | 0,8665 |
| 30 | Түбән Кама | 73 | 0,9733 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 31 | Яңа Чишмә | 74 | 0,9601 |
| 32 | Нурлат | 72 | 0,9868 |
| 33 | Питрәч | 69 | 1,0297 |
| 34 | Балык Бистәсе | 72 | 0,9868 |
| 35 | Саба | 70 | 1,0150 |
| 36 | Сарман | 86 | 0,8262 |
| 37 | Спас | 60 | 1,1842 |
| 38 | Тәтеш | 82 | 0,8665 |
| 39 | Тукай | 81 | 0,8772 |
| 40 | Теләче | 69 | 1,0297 |
| 41 | Чирмешән | 80 | 0,8881 |
| 42 | Чистай | 72 | 0,9868 |
| 43 | Ютазы | 91 | 0,7808 |
| ТР буенча уртача | | 71,05 | 1,0000 |

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 5 декабрендәге 230/2-пр номерлы боерыгына

2нче кушымта

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына

49нчы кушмта

2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары итештерүчеләренә, туфракны төп (көзге) эшкәртүне исәпкә алып, бәйсез ярдәм күрсәтүгә белешмә-исәп-хисап
№ ------- ------- ел, ------
(квартал, ярты ел, 9 ай, ел)

-----------------------------------буенча ИНН
(субсидияләр алучы)

| Чәчү мәйданы, гектар | Бер гектарга минималь ставка, сум | Туфракны төп (көзге) эшкәртүне вакытында төгәлләүне кызыксындыру өчен төзәтмә коэффициенты | Субсидияләргә ихтыяҗ, мең сум (графа 1 х графа 2 х графа 3) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Максатчан акчалар алучының түләү реквизитлары:р/с:
к/с:
БИК
Адрес
Элемтә телефоны:
Тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм:
Оешма - субсидияләр алучының җитәкчесе

____________________________Ф.И.Ат.ис.
(имза)
Баш бухгалтер

________________________________Ф.И.Ат.ис.
(имза)

Мөһер

**Тутырыла:**
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе тарафыннан
**Тапшырыла:**
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына
Даимилек: квартал саен

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 5 декабрендәге 230/2-пр номерлы боерыгына

3нче кушымта

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына
50нче кушымта

2014 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарлары итештерүчеләренә, туфракны төп (көзге) эшкәртүне исәпкә алып, бәйсез ярдәм күрсәтүгә җыелма белешмә-исәп-хисап
№ ------- ------- ел, ------

(квартал, ярты ел, 9 ай, ел)
_______________________________

| Хуҗалыклар исеме | Чәчүлек мәйданы, гектар | Бирелә торган субсидияләрнең күләмен исәпләү | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Бер гектарга минималь ставка, сум | Туфракны төп (көзге) эшкәртүне вакытында төгәлләүне кызыксындыру өчен төзәтмә коэффициенты | Күчерү өчен субсидияләр күләме, мең сум (графа 2 х графа3 х графа 4) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм:
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
______________________муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ___________________________________(Ф.И.Ат.ис.)
______________________
(имза)

Фннанс-икътисад бүлеге башлыгы_____________________________________________(Ф.И.Ат.ис.)
____________________
(имза)

Мөһер

ТР  Премьер  министры  урынбасары – министр                                    М.Г. Әхмәтов

-